

Дубенка районынын Кочкурово урта мәктәбендә Габдулла Тукайнын 135-еллык юбилеен бәйрәм иттек.
Зәнгәр кvк йозендә кояш балкыган чакта, шаулап-горләп яз ае апрель килгәндә, моннан 135 ел элек, 1886 елнын 26 апрелендә Габдулла Тукай доньяга килә.      Ул vзенен кыска вакыт эчендә балкып калган гомеренен һәр минутын халыкка багышлаган һәм vзенен әсәрләрендә балаларны хезмәтне яратырга ойрәткән, зурларны хормәт итәргә ондәгән, татар телебезнен гvзәллегенә дан жырлаган. Кошларны, хайваннарны жәберләмәскә, ә, киресенчә, яратырга, авырлыкларны жинәргә булышырга кушкан. Анын әсәрләре безнен тунган кvнелләребезне эретә, жаннарыбызны жылыта...
Безнен мәктәптә дә анын туган конено багышлап «Тукай иленә сәяхәт» дип исемләнгән кичә vтте. Чараны алып баручылар Каримов Руслан һәм Мусина Джамиля ачып жибәрделәр. Алар Габдулла Тукайнын биографиясен, презентациягә таянып, кыскача сойләделәр. Аннары Тукаебызнын катлаулы тормыш юлы буенча бергәләп схема тозедек. Кичәбезне шигырьләр конкурсы дәвам иттерде. Бик матур итеп укучылар анын шигырьләрен сойләделәр.
Шулай ук Габдулла Тукайнын ижаты буенча рәсемнәр конкурсына нәтижә ясадык. Беренче урынны Рахметуллова Карина яулады, икенчене Каримов Руслан, ә оченчене аердылар Романова Сафира белән Мусина Джамиля. Тукаебызнын тормыш юлы һәм ижаты буенча викторина vткәрдек. Кичә гимнга әверелгән «Туган тел» жыры белән тәмамланды.
Боек Тукаебызнын гомере яшендәй кыска булды. Апрель ае аны бvләк итте безгә, апрель ае алып та китте. Габдулла Тукайнын исеме, тормышы, ижаты мәнге безнен кvнелләрдә яшәр! Якташыбыз Сафия апа Бәширова язган шигыреннән озек белән мәкаләмне тәмамлыйм:

Апрель ае безнен кvнелләрдә
Онытылмаслык булып билгеле.
Язгы кояш безнен Тукаебыз
Йорәкләргә кереп калды әле!

**Альфия УЗБЯКОВА,**
**Дубенка районынын Кочкурово урта мәктәбе укытучысы**